КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 14 май г.Казань № 389

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның беренче абзацына «эшкә алынган» сүзләреннән соң «, авыл хуҗалыгы оешмаларында яки кулланучылар кооперациясе оешмаларында Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча килешүдә (алга таба – килешү) каралган кимендә өч ел эшләргә йөкләмәсен үз өстенә алган» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 4[1] нче пункт өстәргә:

«4[1]. Түләүне бирү максаты – авыл хуҗалыгы җитештерүендә һөнәрләрнең абруен күтәрү һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын һәм һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаганнан соң авыл хуҗалыгы оешмаларында яки кулланучылар кооперациясе оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә ярдәм күрсәтү.»;

6 нчы пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көнне Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;»;

өченче абзацта «Министрлыкның боерыгы белән расланган форма буенча» һәм «(алга таба – килешү)» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «өч көн эчендә» сүзләрен «биш көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

7 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык документларны алар кергән көнне Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки һәм аларны комиссиягә карап тикшерүгә җибәрә.»;

икенче абзацта «10 көн эчендә» сүзләрен «җиде көн эчендә» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «Бер тапкыр һәм ай саен бирелә торган түләүләрне» сүзләрен «Түләүләрне» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 7[1] нче пункт өстәргә:

«7[1]. Яшь белгеч белән авыл хуҗалыгы оешмасы яки кулланучылар кооперациясе оешмасы арасында төзелгән хезмәт шартнамәсе өч ел вакыт үткәнгә кадәр туктатылган очракта (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пункты, 81 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 һәм 4 нче пунктлары, 83 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2, 5 – 7 нче пунктлары белән күздә тотылган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсе туктатылган очраклардан тыш), яшь белгеч хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган түләүнең бер өлешен хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән 30 көн эчендә эшләнмәгән чорга пропорциональ рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты keремeнә кире кайтара.

Бер тапкыр бирелә торган түләүнең бер өлешен кире кайтару вакыты бозылганда, Министрлык бу Тәртипнең 7[1] нче пункты белән билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин